СОВЕТ ПИЖМАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ПЫЖМАРА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«13» март 2023 ел № 71

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге су объектларына ия булу, файдалану, аларны куллану тәртибе турында» 2011 елның 27 июнендә кабул ителгән 31 карары үз көчен югалткан дип тану хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Пыжмара авыл җирлеге Уставына таянып, Прокуратураның 2023 елның 28 февралендәге 02-08-01-2023/Прдп55-23-20920011 номерлы тәкъдиме нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пижмар авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пижмар авыл җирлеге Советының 27.06.2011 елның 31 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Пыжмара авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге милкендәге су объектларына ия булу, файдалану, аларны куллану тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Пыжмара авыл
җирлеге башлыгы Р.Х.Җәләев